| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 с.Старое Дрожжаное № 618

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2019 елның 28 июнендәге 274 номерлы карары белән расланган Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының административ регламентларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль законы, «Реклама турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 16 апреленедәге 106-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 06 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 июлендәге 202-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль законы, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 26 октябрендәге 1742 номерлы «Россия Федерациясе

Хөкүмәте актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, үтәлүе федераль дәүләт транспорт күзәтчелеген, транспорт куркынычсызлыгы өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда чаралар уздырганда бәяләнә торган башкарма хакимият органнары актларының кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен юкка чыгару турында, шулай ук транспорт чараларын техник карау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр турында», «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 июнендәге 274 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының административ регламентларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов